“Татарстан Республикасы
Зеленодол муниципаль районы
Күгәй башлангыч гомуми белем мәктәбе – балалар бакчасы”
Муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесенең
эшчәнлеге турында киң җәмәгатьчелек өчен доклады




2018 ел

## КЕРЕШ

Бу доклад учреждениедә узган уку елында башкарылган эшчәнлек, аның нәтиҗәсе, эш барышында килеп туган авырлыклар һәм белем бирү учреждениесенең алга таба үсешендә төп мәгълүматны туплаган. Без сезне учреждениедәге традицияләр, укыту шартлары, укыту программалары, уку сыйфаты, шулай ук балаларны тукландыру, сәламәтлекне саклау, хезмәт тәрбиясе бирүдә эш нәтиҗәләре белән таныштырырбыз.

Бу доклад белән балалар да, ата-аналар да, Мәгариф идарәсе дә, гомумән, бу елларда кемнәр безнең эшчәнлеккә ярдәм иткән, кемнәр безнең учреждение турында белергә тели - барысы да таныша алалар.

Бүгенге гомуми җыелышта Зеленодол районы Башкарма комитеты җитәкчесе икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары Альберт Шамилевич Гарипов, Җирле үзидарә башлыгы Фәния Хәбибулловна Хисаметдинова, Күгәй күмәк хуҗалыгы җитәкчесе Ирек Галимович Хайруллин катнаша.

## ГОМУМИ ХАРАКТЕРИСТИКА

*Безнең визит карточкабыз*

*Тулы исеме:* “Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Күгәй башлангыч гомуми белем мәктәбе – балалар бакчасы” Муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе.

Күгәй башлангыч гомуми белем мәктәп – балалар бакчасы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе түбәндәге адрес буенча урнашкан: 422516, Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Күгәй авылы, Хайруллин урамы, 11а . Учреждениенең гомуми мәйданы 505 кв.м. Җир участогы 1 гадан артык. Мәктәбебезне яфраклы һәм ылыслы агачлар, куаклар, чәчәк түтәлләре бизәп тора. Бакчада яшелчә һәм җиләк-җимешләр үстерелә. 1 спорт һәм 1 уен мәйданчыгы бар.

| | |
|---|---|
| **Тулы исеме:** | “Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы Күгәй башлангыч гомуми белем мәктәбе – балалар бакчасы” муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе |
| **Кыскартылган исеме:** | МББУ «ТР ЗМР Күгәй БГБМ-ББ». |
| **Юридик адрес:** | 422516, Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Күгәй авылы, Хайруллин урамы, 11а |
| **Учреждениенең тибы, төре, хокукый статусы:** | **тибы буенча:** муниципаль бюджет белем учреждениесе; |

| | |
|---|---|
| | **төре буенча:** башлангыч мәктәп – балалар бакчасы, юридик шәхес. |
| **Учредитель:** | Учредитель булып Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының Муниципаль катламы тора, аның вәкаләтләрен Зеленодол муниципаль районының Башкарма комитеты башкара. Күгәй башлангыч гомуми белем мәктәбе – балалар бакчасы Мәгариф идарәсе кул астында эшли. |

Учреждениедә уку-укыту эшчәнлеге тиешле документлар белән тәэмин ителгән.

| **Юридик шәхес буларак эшчәнлеген тәэмин итүгә характеристика** | **Тиешле документлар** |
|---|---|
| 1. Уку-укыту эшчәнлеген алып баруга лицензия. | Серия 16 Л 01 №0005909 Теркәлү номеры № 9781 от 25.09.2017 ел, бессрочно |
| 2.Дәүләт аккредитациясе үтү турында шаһәдәтнамә. | Теркәлү номеры №2334 от 28.12.2012 ел. |
| 3. Устав | Татарстан Республикасы Зеленодол районы Башкарма комитеты карары белән расланган 28.08.2017 ел, №2266 |
| 4. Салым инспекциясендә теркәлү шаһәдәтнамәсе. | Серия 16 №006258281, 30.04.1998 ел. |
| 5. Бердәм дәүләт реестрында теркәлү шаһәдәтнамәсе. | Теркәлү номеры 1021606755477 30.04.2013 ел. |
| 6.Санитар-эпидемиологик нәтиҗә. | №16.20.01.110.М.000127.08.11, 19.08.2011 ел. |
| 7. Янгын куркынычсызлыгы буенча нәтиҗә. | №7, 30.04.2013 ел. |

| **Территория** | **Күгәй авылы, Х.Хайруллин урамы, 11а йорты** |
|---|---|

| | |
|---|---|
| Гомуми мәйдан | 12153 кв. м |
| Яшелләндерү мәйданы | 11648 кв. м |
| Учреждение бинасы мәйданы | 505 кв. м |
| Балалар бакчасы | 187 кв. м |
| Башлангыч мәктәп | 318 кв. м |
| Спорт залы | 65 кв. м. |
| Азык-төлекне саклау һәм ашарга әзерләү бүлеге | 28 кв. м |
| Кер юу почмагы | 10 кв. м |

Уку-укыту эшчәнлегендә төп уку-укыту программалары:
- балалар бакчасында гомум белем бирү – 5 ел;
- башлангыч гомум белем бирү – 4 ел.

***Телефон, факс***: 8(84371) 2-50-02
***Электрон почта адресы***: **kugeev@yandex.ru**

*Директор:* Шайхнурова Гөлнара Рашидовна, югары белемле, 1 нче квалификацион категориягә ия.

*Учреждениенең максаты:* Федераль дәүләт белем бирү стандартларын үзләштерү шартларында тормышта үз урынын табарга сәләтле иҗади шәхес формалаштыру.

Учреждениедә тәрбия-белем бирү эшчәнлеге түбәндәдәге норматив-хокукый документларга нигезләнеп оештырыла:

1. 2012елның 29 декабрендә чыккан № 273 «Об образовании в Российской Федерации» Федераль законы;

2. 24.07.1998 елда чыккан №126-ФЗ Россия Федерациясенең «Телләр турында»гы законы;
3. Белем бирү учреждениесе турында типовой положение (23.12.2002 елда Россия Федерациясе хөкүмәте карары белән расланган, №919)
4. Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2009 елның 6 октябрендәге «Башлангыч гомум белем бирүдә Федераль дәүләт белем бирү стандартларын раслау һәм кертү» турындагы №373 карары. (18.12.2012 елда ред.);
5. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 08.10.2010 елдагы «Физик культураның өченче сәгатен кертү» турындагы № ИК-1494/19 хаты.;

6. СанПиН таләпләре 2.4.2. 2821-10 «Белем бирү учреждениеләрендә уку-укытуны оештыру шартларында санитар – эпидемиологик таләпләр» (Россия Федерациияcенең юстиция Министрлыгында 2011 елның 3 мартында теркәлгән, теркәлү номеры № 1994);
7. СанПиН таләпләре 2.5.3157-14 «Белем бирү учреждениеләрендә уку-укытуны оештыру шартларында санитар – эпидемиологик таләпләр» (2014 елның 21 гыйнварында гамәлгә кергән).
8. Татарстан Республикасының «Мәгариф турындагы» законы;
9. Татарстан Республикасының 18.07.2004 елдагы №44ЗРТ «Телләр турындагы» законы;
10. «Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы Күгәй башлангыч гомуми белем мәктәбк – балалар бакчасы» Муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе Уставы һәм уку-укыту программалары;
11. Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының 03.03.2012 елдагы №16 методик тәкъдиме: мәктәпкәчә яшьтәге балаларга татар (рус) телләрен өйрәтүне оештыру буенча;
12. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 20.01.2013 елдагы № 968/13 хаты: “Об эффективности внедрении новых УМК”.

*Учреждение турында кыскача белешмә:* Безнең белем учреждениесендә 2 яшьтән алып 11 яшькә кадәр балалар тәрбия һәм белем алалар.

Башлангыч мәктәпкә Устав һәм Кабул итү тәртибе буенча ата-ана гаризасы нигезендә 6,6 яше тулган балалар укырга алына. Балалар бакчасына Устав һәм Кабул итү тәртибе буенча ата-ана гаризасы нигезендә 2 яшьтән балалар кабул ителә. 2017-2018 уку елында балалар бакчасы 12 бала белән комплектлаштырылды. 9 бала ата-аналар түләвенең 50% ташламасыннан, 1 бала бала ата-аналар түләвенең 100% ташламасыннан файдаланды. 3 балага -20% , 2 балага – 50%, 3 балага -70% ата-аналар түләвеннән компенсация каралды һәм бу компенсация һәр балага да вакытында кайтарылып барылды.

Күгәй башлангыч мәктәбен тәмамлаган укучылар Норлат урта мәктәбенең 5 сыйныфында укуларын дәвам итәләр. Ике автобус иртәнге 7.10 да һәм 7.40 да аларны Үзәктән алып китә, дәресләр беткәч кире кайтара.

Уку елы озынлыгы - 35 атна (беренче сыйныф укучылары өчен - 33 атна), Башлангыч мәктәптә 2 класс-комплект, анда - 11 укучы, дәресләр озынлыгы – 45 минут. 1 сыйныфлар 5 көнлек, 2-4 сыйныфлар 6 көнлек уку атнасы буенча белем алалар. Балалар бакчасында 6 көн дәвамында 9 сәгатьлек эш режимы белән шөгыльләнәләр.

***Таблица №1.*** *Укучылар һәм тәрбияләнүчеләр турында өч еллык гомуми белешмә*

| Статистика буенча кеше саны | 2015-2016 уку елы | 2016-2017 уку елы | 2017-2018 уку елы |
|---|---|---|---|
| 1. Барлыгы | 25 | 24 | 23 |
| • балалар бакчасында | 16 | 12 | 12 |
| • башлангыч мәктәптә | 9 | 12 | 11 |
| 2. Икенче уку елына калдырылган | - | - | - |
| 3. Шартлы рәвештә күчерелгән | - | - | - |
| 4. Уку алдынгылары (бишле билгеләренә генә өлгерүчеләр) | 1 | 1 | 1 |

## ПЕДАГОГИК КОЛЛЕКТИВ

Учреждение, Россия Федерациясенең белем һәм тәрбия бирү системасы юнәлешләре буенча куелган максат һәм бурычларны заман таләпләренә туры китереп чишә алырлык тотрыклы, белемле укытучылар һәм тәрбиячеләр белән тәэмин ителгән.

*Педагогик коллектив:* Күгәй башлангыч мәктәп – балалар бакчасында иҗади эшләүче педагоглар коллективы тупланган. Бездә барлыгы 6 педагог эшли: 3 укытучы, 3 тәрбияче. Коллективның уртача яшь озынлыгы – 40 яшь. 3 педагог югары белемле, урта махсус белем белән 3 педагог эшли. Уртача педагогик стаж – 20 ел. Биш педагог беренче квалификацион категорияле. Педагогик коллектив һәм администрация эшенең мөһим юнәлеше булып укытучы һәм тәрбиячеләрнең педагогик белемнәрен квалификация күтәрү курсларында һәм аттестация үтү юлы белән арттыру тора. Моның өчен педагоглар даими рәвештә квалификация күтәрү курсларында булалар, аттестация үтәләр, моннан тыш өйрәтү семинарларында, мастер-классларда катнашалар..

Алар арасында:

| | Кеше саны | % |
|---|---|---|
| Югары белемле педагоглар | 3 | 50 % |
| Махсус урта белемле педагоглар | 3 | 50 % |
| I квалификацион категорияле | 5 | 84 % |
| 10 елга кадәр эш стажы | - | - |
| 10 елдан 25 елга кадәр эш стажы | 3 | 50 % |
| 25 елдан артык эш стажы | 3 | 50 % |










Эшләүче педагоглар үз эшләрендә яңа технологияләрне уңышлы кулланалар, үз белемнәрен күтәрү өстендә даими эш алып баралар. Педагоглар район һәм республика күләмендә үткәрелә торган семинарлар, киңәшмәләрдә катнашалар, чыгышлар ясыйлар.

**БҮГЕНГЕ ЯШӘЕШЕБЕЗ**

Ата-аналар арасында югары уку йортын тәмамлаучылар саны – 10, һөнәри техникум, колледж тәмамлаучылар саны – 4, һөнәри училище тәмамлаучылар – 12, урта белемлеләр – 4.

***Таблица №2. Ата-аналарның белем дәрәҗәсе (2017-2018 уку елы )***

| | |
|---|---|
| Югары уку йортын тәмамлаучылар (югары белемле ) | 10 |
| Һөнәри техникум, колледж тәмамлаучылар (махсус урта белемле) | 4 |
| Һөнәри училище тәмамлаучылар (башлангыч һөнәри белемле) | 12 |
| Урта белемле | 4 |

2017 – 2018 уку елында ата-аналарның уналты - хезмәткәр, эшчеләр саны – 11.

***Таблица №3. Ата-аналарның эш белән тәэмин ителүе (2017-2018 уку елы)***

| | |
|---|---|
| Хезмәткәрләр | 16 |
| Эшчеләр (сезонлы эшләрне исәпкә алып) | 11 |
| Вакытлыча эшсезләр | 3 |







Узган уку елында учреждениедә барлык бала саны – 23 иде, шуларның 21е тулы гаиләдән, гаиләләрнең бишесе - күп балалы гаилә.

***Таблица №4. Балаларның гаилә хәле (2017 – 2018 уку елы)***

| Критерийлар | Мәктәпкәчә тәрбия төркеме | Башлангыч мәктәп | Барлыгы |
|---|---|---|---|
| Барлык бала саны | 12 | 11 | 23 |
| Тулы гаиләдән | 10 | 8 | 21 |
| Тулы булмаган гаиләдән | 2 | 1 | 3 |
| Шулардан | | | |
| Күп балалы гаилә | 5 | 0 | 5 |
| Гаиләдә 2 бала булган гаилә | 2 | 6 | 8 |
| Гаиләдә 1 бала булган гаилә | 1 | 2 | 5 |
| Авыр гаиләләр | | - | - |
| Баланы тәрбиягә алучы гаилә | 1 | - | 1 |

Барлык ата-аналар да учреждение тормышында актив катнаша, балаларның укуы белән даими кызыксына.

***Таблица №5 Ата-аналарның балаларның укуы белән кызыксынучанлыгы (2017 – 2018 уку елы)***

| | |
|---|---|
| Балаларның белем алуы белән кызыксыналар | 100% |
| Балаларның белем алуы белән кызыксынмыйлар | - |

***Таблица №6. Ата-аналарның мәктәп белән берлектә эшләүләре (2017 – 2018 уку елы)***

| | |
|---|---|
| Мәктәп белән берлектә эшлиләр | 100% |
| Мәктәп белән берлектә эшләргә теләмиләр | - |

***Таблица №7. Укучылар санындагы үзгәрешләр***

| Укучылар саны | 2015-2016 уку елы | 2016-2017 уку елы | 2017-2018 уку елы |
|---|---|---|---|
| Ел башында | 9 | 12 | 11 |
| 1 сыйныф | 3 | 3 | 3 |
| Китүчеләр | - | 1 | - |
| Килүчеләр | - | - | - |
| Куылучылар | - | - | - |
| Уку елы ахырында | 9 | 11 | 11 |

1 сыйныфка керүчеләр саны авылда туучылар саны белән, ә балаларның аз булуы авылда яшь гаиләләрнең аз калуына бәйле. Алдагы 3 елда 1 сыйныфка керүчеләр саны стабиль 2-3 тирәсе була, балалар


бакчасында күрше Акъегет, Сүнчәләй авылларыннан балалар йөрү хисабына, күчеп кайтучы гаиләләр хисабына балалар төркеме тулыландырыла.

2017-2018 уку елында, башка еллардагы кебек үк, авыл җирлегендә яшәүче, 1 сыйныфка керергә тиешле 3 бала укырга керде.

***Таблица №8 Алдагы уку елларына укучылар һәм балалар саны***

| Статистика буенча балалар саны | 2018-2019 уку елы | 2019-2020 уку елы | 2020-2021 уку елы | 2021-2022 уку елы |
|---|---|---|---|---|
| 1. Барлыгы | 21 | 21 | 21 | 18 |
| • балалар бакчасында | 13 | 12 | 12 | 10 |
| • башлангыч мәктәптә | 8 | 9 | 9 | 8 |

## БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕН ИДАРӘ ИТҮ ТӨЗЕЛЕШЕ






**Белем бирү учреждениесенең төп эш юнәлешләре**:

- укыту-методик эш;
- тәрбия эше;
- административ-хуҗалык эшләре;
- куркынычсызлык булдыру;
- ата-аналар белән тыгыз мөнәсәбәт урнаштыру;
- җәмәгатьчелек белән тыгыз элемтә оештыру.

Бөтен юнәлешләрнең эшчәнлеге Зеленодол муниципаль районы Башкарма комитетының карары белән 2017 нче елнын 28 нче августында, 2266 нчы номер белән кабул ителгән Устав нигезендә алып барыла. Административ җитәкчелекне директор башкара. Директорның төп вазифасы - укыту һәм тәрбия эшендә катнашучыларны бергә туплап куелган максатларга ирешүне булдыру. Идарә итүнең иң югары органы булып Педагогик совет, Хезмәткәрләрнең гомуми быелышы, Ата-аналарның гомуми җыелышы, Учреҗдение Советы тора. Педсовет һәм Ата-аналар җыелышына учреждение Советы күзәтчелек итә. Педагогик советның тематикасы ел саен август ае утырышында Учреждениеның яңа уку елына планын кабул иткәндә карала. Ул елга 4 мәртәбә үткәрелә, шулай ук кече педсоветлар да үткәрелергә мөмкин. Гомуми ата-аналар җыелышлары планы шулай ук уку елы башында кабул ителә. Барлыгы 4 гомуми җыелыш үткәрелә. Аудиториядә төрле темаларга лекцияләр укыла, әти-әниләр белән әңгәмәләр, түгәрәк өстәлләр, анкеталаштыру, мастер-класслар уздырыла. Әти-әниләр учреждениедә үткәрелә торган чараларда бик теләп катнашалар. Балалар, педагоглар белән берлектә бәйрәмнәр оештыралар.

Ата-аналар комитеты - ата-аналарның уку-укыту процессында катнашучы буларак хокукларын һәм бурычларын тәэмин итүче орган. Ул педагоглар белән берлектә учреждениенең Үсеш программасын тормышка ашыруда катнаша.

Учреждение Советы идарә итүдә иң югары орган, чөнки ул уку-укыту процессында катнашучыларның барысының да мәнфәгатьләрен чагылдыра. Учреждение Советы үзидарәне үстерүдә, коллектив эшчәнлеген алып баруда, уку-укыту процессын һәм финанс-хуҗалык эшләрен оештыруда килеп туган мәсьәләләрне чишүдә катнаша.

Киңәшләшү органы булып учреждениеның методик советы, педагогларның ижади төркемнәре тора. Алар уку-укытуга кагылышлы мәсьәләләрне чишүдә зур роль уйныйлар.

Учреждение эшчәнлеген алып баруда катнашучы органнарның һәрберсе Уставка һәм учреждениенең локаль актларына нигезләнә.

## УКУ-УКЫТУ ЭШЧӘНЛЕГЕН АЛЫП БАРУ ШАРТЛАРЫ

### Материаль-техник база

Белем бирү учреждениесендә уку-укыту эшчәнлеген алып бару өчен барлык кирәкле шартлар да тудырылган: кабинетлар, спорт залы, балалар уйнау өчен мәйданчык һәм спорт мәйданчыгы, әдәби һәм фәнни әдәбиятка бай китапханә бар. 1

Учреждение компьютерлар, ноутбуклар, интерактив такта, проекторлар, экран, планшет, синтезатор, магнитофоннар, телевизор, DVD, ксерокс, сканер һәм башка техник средстволар белән җиһазландырылган. Компьютерлар, ноутбуклар Интернет челтәренә тоташтырылган, мәктәп сайты уңышлы эшләп килә.2 Учреждениедә үзәкләштерелгән белем бирү ресурслары коллекциясе: төрле фәннәр буенча диск һәм аудиокассеталар тупланган. Мәктәп укучылары федераль исемлеккә кертелгән дәреслекләр белән тулысынча, педагоглар укыту программалары һәм дидактик материаллар белән тәэмин ителгән. 3 Дәресләрдә һәм дәрестән тыш эшчәнлектә балаларга белем төрле чыганаклар аша бирелә. Федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә укучы үзлегеннән дә өстәмә белем үзләштерүдә шөгыльләнергә тиеш. 4 Мәктәптә педагоглар тулысынча электрон журналлар белән генә эшлиләр, укучылар электрон көндәлекләрдән файдаланалар. Республикабызда электрон хезмәтләр шактый популярлашты. Учреждениедә документларны электрон формада алып бару үстерелә: учреждение паспорты, учреждение сайты, укучыларның шәхси карталары, электрон журналлар, электрон көндәлекләр, электрон балалар бакчасы сайты, педагогларның шәхси сайтлары.

Группа тиешле җиһазлар, дидактик материаллар, уенчыклар белән тәэмин ителгән. Шулай ук программада каралган күрсәтмә материаллар, альбомнар, матур әдәбият әсәрләре балаларның белемнәрен төрле яклап үстерә, баета. Дидактик уеннар, сюжетлы уен наборлары, конструкторлар өстәл уеннары, бармак уеннары, рәсем сәнгате һәм физик культура эшчәнлегендә кирәкле әсбаплар һәрдаим кулланыла.

### Учреждениенең укыту планы. Эш режимы.

Муниципаль белем учреждениесе белем бирүдә даимичәнлек һәм дәвамчанлык принципларына нигезләнеп эшли. Мәктәптә 1-4 сыйныф

укучылары Федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә “Перспектива” программасы буенча белем ала, шулай ук балалар бакчасындагы тәрбияләнүчеләр Федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә төзелгән Н.Е.Веракса, М.А.Васильева программасы буенча шөгыльләнәләр.
Шулай ук С.М.Гаффарованың «Изучаем русский язык» программасы
- «Обучение детей основам безопасного поведения на дорогах» - Региональ стандарт.

Укытуның төп формасы булып сыйныф-дәрес системасы тора.

Укыту планын төзегәндә сыйныфлар арасындагы дәвамчанлык, фәннәр арасындагы бәйләнеш сакланды. Укучылар өчен атналык эш күләме тиешле дәрәҗәдән артмады.

1 – 4 сыйныфлар өчен төзелгән укыту планы балаларга дүртьеллык башлангыч белем алуга юнәлдерелгән.

Эш режимы: Санитар-эпидемиологик кагыйдәләр буенча 1 сыйныфлар өчен 5 көнлек уку атнасы вакытында атнага 21 дәрес һәм дәресләр озынлыгы беренче чиректә 35 минут, ә икенче чиректән 45 минут, 2-4 сыйныфлар өчен 6 көнлек уку атнасы вакытында атнага 26 дәрес һәм дәресләр озынлыгы 45 минут. Шул ук вакытта дәүләт стандартларың федераль компонентында һәр фән өчен каралган сәгатьләр саны һәм укыту эчтәлеге тулысынча саклана.

Укыту түләүсез, бер сменада алып барыла. Дәресләр 8.00. сәгатьтә башлана. Каникуллар уку елы дәвамында 30 календарь көн, 1 сыйныфлар өчен февраль аенда бер атналык өстәмә каникул каралган.

Дәрестән тыш һәм сыйныфтан тыш эшчәнлек шәхеснең үсешен, фәннәр буенча белемнәрне тирәнәйтүне күздә тота. Дәрестән тыш эшчәнлек түбәндәге юнәлешләр буенча оештырылды: “Сәламәт булып үс” – сәламәт яшәү рәвеше тәрбияләү, “Туган телем – иркә гөлем” – гомуми интеллектуаль үсеш. Моннан тыш, Мәдәният йортында оештырылган “Тамчылар” җыр һәм “Сәйләннәр” бию түгәрәгендә 15%, “Яшь көрәшче” һәм спорт түгәрәкләрендә 85% бала йөри. Ел дәвамында алар төрле республика, район күләмендә оештырыла торган һәм зональ турнирларда катнашалар, призлы урыннар алалар.

Балалар бакчасында да, мәктәптә дә дәресләрдә педагоглар Федераль дәүләт белем стандартлары буенча эшлиләр, балаларга фәннәр буенча тирәнтен белем бирү, логик фикерләүләрен үстерү, сөйләм һәм аралашу культурасын тәрбияләү өстендә эш алып баралар.

Укыту планнары түбәндәге эш нәтиҗәләрен максат итеп куя:

- балалар һәм ата-аналарның белем алуга карата теләкләрен канәгатьләндерү;
- белем һәм күнекмәләрнең сыйфатын күтәрү;
- балаларның иҗади сәләтләрен үстерү өчен уңайлы шартлар тудыру;
- укытуда дәвамчанлыкны саклау.

**2017-2018 уку елына**
**1-4 сыйныфлар өчен укыту планы**
**(укыту татар телендә бара)**

| Уку фәннәре | Сыйныфлар | | | | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|
| | **1** | **2** | **3** | **4** | |
| | Атнага сәгать саны | | | | |
| Рус теле | 2 | 4 | 3 | 4 | 13 |
| Әдәби уку | 2 | 2 | 2 | 2 | 8 |
| Туган тел | 3 | 3 | 4 | 3 | 13 |
| Туган телдә әдәби уку | 2 | 2 | 2 | 2 | 8 |
| Чит тел (инглиз) | - | 2 | 2 | 2 | 6 |
| Математика | 4 | 4 | 4 | 4 | 16 |
| Әйләнә-тирә һәм ТИН | 2 | 2 | 2 | 2 | 8 |
| Сәнгать (музыка һәм сынлы сәнгать) | 2 | 2 | 2 | 2 | 8 |
| Технология (хезмәт) | 1 | 1 | 1 | 1 | 4 |
| Физкультура | 3 | 3 | 3 | 3 | 12 |
| Россия халыкларының рухи-әхлакый мәдәният нигезләре | | | | 1 | |
| Барлыгы | 21 | 25 | 25 | 26 | 97 |
| Белем учреждениесе компоненты<br>Рус теле | | 1 | 1 | | 2 |
| Укыту атнасында каралган эш күләме | **21** | **26** | **26** | **26** | **99** |

Башлангыч белем программаларын сыйфатлы үзләштерү максатыннан мәктәп компоненты сәгатьләре 2-3 сыйныфларда рус теленә, 4 сыйныфта (ата-аналар ризалыгы нигезендә) Россия халыкларының рухи-әхлакый мәдәният нигезләре фәненә бирелде.

Чит тел (инглиз теле) 2 сыйныфтан укытыла. Әлеге фән буенча материалны үзләштерү өчен укыту планындагы сәгатьләр саны тиешле күләмдә бирелгән. 1 сыйныфларда шулай ук өстәмә юнәлеш буларак атнага 1 сәгать кертелә.

Фән һәм Мәгариф министрлыгының 2014 елның 25 февралендә язылган 2744/14 номерлы хаты һәм Мәгариф идарәсе боерыгы нигезендә 2014 елның 1 мартыннан алып уку елы ахырына кадәр башлангыч сыйныф укучыларына татар теленнән атнага бер өстәмә дәрес укыту кертелде.

**Балалар бакчасында укыту эшчәнлеге**

***Предметно – развивающая среда*** в детском саду способствует развитию ребенка по всем направлениям. Все группы оснащены в соответствии с возрастом, полом детей, оборудованием для групповой и продуктивной деятельности.

При планировании игровых уголков созданы условия, стимулирующие мыслительную и свободную, самостоятельную речевую деятельность детей. Спроектированная таким образом предметно-развивающая среда группы даёт ребёнку новые средства и способы познания и преобразования мира, побуждает детей к общению между собой и воспитателем, тем самым формируется познавательная и речевая активность детей.

Предметно-развивающая среда организована так, чтобы каждый ребенок имел выбор деятельности, мог реализовать свои интересы, потребности. Пространство детского сада – особая среда творческой жизнедеятельности, которая постоянно изменяется.

Основными направлениями в работе детского сада являются осуществление комплексной воспитательной работы с детьми, внедрение новых технологий, обеспечивающих охрану и укрепление физического и психического здоровья детей, воспитание детей по основным ведущим линиям развития, сохранение и поддержка индивидуальности ребенка.

Два раза в неделю во вторую половину дня и в субботу опытные педагоги вводят детей в интересный мир познания, творчества, музыки, фольклора и искусства. Кружковая деятельность проводится педагогами ДОУ по программам дополнительного образования с соблюдением необходимой максимально допустимой нагрузки детей по следующим направлениям:

“Нәни эколог” Хайруллина Г.Г.;
“Әкият илендә” Загидуллина Р.Н.;
“Сәламәт булыйк” Сабирзянова А.Р.

Балалар бакчасында балаларның төрле яклап үсеше өчен шартлар тудырылган. Материаль-техник база заман таләпләренә туры килә: кабул итү, уен, йокы, туалет, буфет бүлмәләре бар. Белем һәм тәрбия бирү процессын дәүләт стандартларына яраклаштырып алып барыла, предмет-үсеш тирәлеген балалар яшенә туры китереп җиһазландырылган. Группа тиешле җиһазлар, дидактик материаллар, уенчыклар белән тәэмин ителгән. Шулай ук программада каралган күрсәтмә материаллар, альбомнар, матур әдәбият әсәрләре балаларның белемнәрен төрле яклап үстерә, баета. Дидактик уеннар, сюжетлы уен наборлары, конструкторлар, өстәл уеннары, бармак уеннары, рәсем сәнгате һәм физик культура эшчәнлегендә кирәкле әсбаплар һәрдаим кулланыла.

Балалар бакчасында иң гади математик күзаллауны формалаштыру, әдәби әсәрләр, милли уеннар, гореф-гадәтләр белән таныштыру, физик тәрбия - сәламәтләндерү, сөйләм үстерү, рус теле, әйләнә-тирә дөнья, грамота

нигезләрен үзләштерү, музыкаль сәнгатъ эшчәнлеге, экологик тәрбия, иҗади сәнгать эшчәнлеге: рәсем, әвәләү, кисеп ябыштыру буенча шөгыльләр үткәрелә.

Дәресләр челтәре балалар бакчасында 2014 елның 21 гыйнварында гамәлгә кергән СанПин (2.5.3157-14) нормаларына нигезләнеп төзелә.

2 кечкенәләр төркемендә шөгыль дәвамлыгы 15 минут, шөгыльләр арасында 10 минутлык ял уздырыла. Көн дәвамында 2 шөгыль, атнага бер тапкыр 3 шөгыль каралган - физик тәрбия саф һавада үткәрелә.

Уртанчылар төркемендә шөгыль озынлыгы - 20 минут, шөгыльләр арасында 10 минутлык ял. Көн дәвамында 3 шөгыль, атнага бер тапкыр физик тәрбия саф һавада үткәрелә.

Мәктәпкә хәзерлек төркемендә шөгыль озынлыгы - 30 минут, шөгыльләр арасында 10 минутлык ял. Көн дәвамында 3 шөгыль, атнага бер тапкыр 4 шөгыль - физик тәрбия саф һавада үткәрелә. Барлык төркемнәрдә дә шөгыльләр көннең беренче яртысында уздырыла. Балаларның яшьләренә карап, төркемнәр буенча физкультминуткалар оештырыла.

Шөгыльләр челтәрен төзегәндә эшчәнлекне төрләндерү принципы күздә тотыла. Һәр төркемдә көн саен физик тәрбия яки музыка тәрбиясе шөгыльләре бар. Атнаның беренче көннәрендә балаларга үзләштерү авыррак булган фәннәр буенча шөгыльләр оештырыла.

Балаларның белем дәрәҗәсен ачыклау максатыннан ел башында һәм ел барышында ике мәртәбә диагностика үткәрелә. Нәтиҗәләр буенча балаларның үсешен күрсәткән мониторинг төзелә.

Балалар белән ел дәвамында күңел ачу уеннары һәм бәйрәмнәр уздырыла. Балалар үз-үзләрен тыныч, шат күңелле, өлкәннәр тарафыннан якланган итеп тойсыннар өчен, төркемдә һәм балалар бакчасында уңай эмоциональ шартлар тудырылган. Ком-су зонасы, хәрәкәт, үстерешле белем бирү, экология, уен почмаклары бар. Рус һәм татар теле почмаклары булдырылды. Балалар кече яшьтән ике телдә дә аралашырга, төрле очракларда аны кулланырга өйрәнәләр. Балалар өчен матур әдәбият, яңа укыту методик комплектлары, дидактик, күрсәтмә, таратма материаллар, эш дәфтәрләре, мультимедиа чаралары тиешле дәрәҗәдә файдалынила. Театральләштерелгән тирәлектә театральләштерү һәм уеннар өчен кирәкле җиһазлар тупланган: балалар костюмнары, бармак уеннары өчен курчаклар һәм декорация тупланган. Бу җиһазлар балаларның үзләре белгән әкиятләр, шигырьләр, җырлар буенча тамашалар уйнау осталыкларын үстерүгә хезмәт итә, башкару осталыкларын камилләштерә. Төрле чараларда катнашып балаларның иҗади мөмкинлекләре, сәләтләре ачыла.

Балаларны юлда йөрү кагыйдәләренә еллык план нигезендә өйрәтүне алып барылды. Шулай ук аерым почмак булдырылды. Бу балаларда зур кызыксыну уята, аларны уеннарда активлаштыра. Балалар бакчасы территориясендә предмет-үсеш тирәлеге балаларның тормышларын һәм сәламәтлекләрен күз уңында тотып оештырыла. Жәйге веранда, комлыклар, уен зоналары, кече спорт формаларын яңартып косметик ремонт ясалды. Табигать почмагында балалар гөлләрне тәрбиялиләр: сулар сибәләр,

төпләрен йомшарталар, тузаннарын сөртәләр. Моның өчен эш кораллары булдырылды, алъяпкычлар тегелде.Бу балаларга экологик тәрбия белән бергә хезмәт тәрбиясе бирергә дә ярдәм итә. Балалар тирә - юньне чистартуда булышалар, чәчәкләргә сулар сибәләр, карлар көрәп карыйлар. Яз җиткәч чәчәк, яшелчә үсентеләре, суган утыртабыз. Балалар һәрбер чыккан яшел үсентене көтеп ала, аның өчен чын күңелдән шатланалар. Учреждение тирәсендә ел саен күп төрле чәчәк үстерәбез, укучылар, әти-әниләр ярдәмендә күпьеллык чәчәкләр утыртып та, яз көне чәчәк үсентесе утыртып та мәктәп-бакча тирәсен чәчәкләргә күмәбез.

Шулай ук ел ел дәвамында башлангыч мәктәп белән тыгыз элемтә алып барылды. Балалар белән белем көненнән башланып киткән бәйләнеш ел дәвамында сузылды: мәктәпнең китапханәсенә, ашханәгә экскурсияләргә бардылар, башлангыч класс балаларының дәресләрендә булдылар, башлангыч класс укучылары да бакчада шөгыльләр карадылар, бик күп бәйрәмнәрне бергәләп үткәрдек: Яңа ел, шигырь бәйрәме, балалар сабантуе, чыгарылыш бәйрәмнәре.

Мәктәп белән бакча арасында тыгыз элемтә булдыру – балаларга белем һәм тәрбия бирүдәге туган авырлыкларны җиңел чишәргә ярдәм итә.

Бездә балалар бакчасына түләү уртача – 3070 сум, ярты бәясен 1535 сум түләүдә - балалар саны – 9 әү. 2017-2018 уку елында 2677 бала көне , 260 эш көне булды.

## УКЫТУ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Тулаем алганда учреждениедә укыту сыйфаты тотрыклы. Эшнең төп күрсәткече - 4 сыйныф чыгарылышы һәм балалар бакчасының мәктәпкәчә әзерлек төркеме.

Балалар бакчасында системалы рәвештә программаны үзләштерү буенча анализ ясала. Балаларның белем дәрәҗәләренең нәтиҗәләре турында әти-әниләргә җыелышларда хәбәр ителә. Мәктәпкәчә әзерлек төркемендә өлгереш 83%, ягъни барлык балалар да программаны үзләштергән, уку сыйфаты 50% .

| Программа бүленешләре | 2015-2016 | | 2016-2017 | | 2017-2018 | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Белем дәрәҗәсе | | Белем дәрәҗәсе | | Белем дәрәҗәсе | |
| 1.Иҗади сәнгать эшчәнлеге | югары | 4 | югары | 2 | югары | 4 |
| | уртача | 12 | уртача | 10 | уртача | 8 |
| | түбән | - | түбән | - | түбән | - |
| 2.Танып белү эшчәнлеге | югары | 4 | югары | 3 | югары | 6 |
| | уртача | 12 | уртача | 9 | уртача | 6 |
| | түбән | - | түбән | - | түбән | - |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.Физик тәрбия | югары | 2 | югары | 4 | югары | 6 |
| | уртача | 14 | уртача | 8 | уртача | 6 |
| | түбән | - | түбән | - | түбән | - |
| 4.Социаль-коммуникатив эшчәнлек | югары | 5 | югары | 5 | югары | 4 |
| | уртача | 11 | уртача | 7 | уртача | 8 |
| | түбән | - | түбән | - | түбән | - |
| 5.Сөйләм үстерү эшчәнлеге | югары | 3 | югары | 4 | югары | 4 |
| | уртача | 13 | уртача | 5 | уртача | 6 |
| | түбән | - | түбән | 3 | түбән | 2 |

## 4 сыйныфта укыту сыйфаты нәтиҗәләре


4 сыйныфларда рус теле, математика, әйләнә-тирә дөнья фәннәреннән ВПР (бөтенроссия тикшерү эшләре) үткәрелә.мониторинг үткәрелеп килә. 4 сыйныфта, инглиз теленнән федераль мониторинг, шулай ук предметара проект эше нәтиҗәләре буенча укучыларның фәннәр буенча уртача – 4,5 билгесе.

| Предмет / Уку елы | Рус теле | Математика | Әйләнә-тирә | Инглиз теле |
|---|---|---|---|---|
| 2016-2017 | 3,6 | 5 | 4 | 4 |
| 2017-2018 | 4,2 | 4,5 | 4 | 4,2 |

## Укучыларның уку сыйфаты нәтиҗәләре

| Уку елы | Мәктәп буенча уку сыйфаты | 4 сыйныфта уку сыйфаты |
|---|---|---|
| 2015-2016 | 72% | - |
| 2016-2017 | 55% | 33% |
| 2017-2018 | 66% | 75% |

Төрле фәннәр буенча башлангыч сыйныфларда уку сыйфаты.




Аннан алдагы уку елында башлангыч мәктәпне тәмамлаган укучыларның чагыштыру буенча 5сыйныфта да белем дәрәҗәләре түбән төшми.

Балаларның иҗади сәләтен ачыклау һәм үстерүдә фәннәр буенча мәктәп күләмендә үткәрелгән олимпиадалар, муниципаль олимпиадалар, онлайн, электрон олимпиадалар һәм аң-белем, зиһен үстерү конкурслары зур әһәмияткә ия.

Укучылар мәктәп, район, өлкә күләмендә үткәрелә торган чараларда: конкурслар, спорт ярышларында катнашалар һәм урыннар алалар.

**Фәннәр буенча үткәрелә торган төрле дәрәҗәдәге чараларда катнашу**

| № | Чаралар | Дәрәҗә | Катнашучылар |
|---|---|---|---|
| 1 | Математика фәне буенча «Кенгерә» уен-конкурсы | Дәүләтара | Укучыларның 54% |
| 2 | «Русский медвежонок» уен-конкурсы | Федераль | Укучыларның 54% |
| 3 | «Английский бульдог» уен-конкурсы | Федераль | Укучыларның 18% |
| 4 | «Табигать һәм кеше» уен-конкурсы | Федераль | Укучыларның 54% |
| 5 | Учи.ру сайтында математикадан халыкара онлайн олимпиада | Дәүләтара | Укучыларның 63% |
| 6 | Учи.ру сайтында рус теленнән халыкара онлайн олимпиада | Дәүләтара | Укучыларның 63% |
| 7 | Учи.ру сайтында предметара онлайн олимпиада | Дәүләтара | Укучыларның 36% |

## УЧРЕЖДЕНИЕДӘ ТӘРБИЯ ЭШЕ

Тәрбия эшенең төп максаты булып ирекле, кешелекле, мөстәкыйль, ныклы белемле, иҗади эшкә әзер һәм әхлаклы шәхес тәрбияләү тора.

Әлеге максатка ирешү өчен педагоглар алдында түбәндәге бурычлар куелган:

- тирә-юньдәге кешеләргә, вакыйгаларга сабырлык, түзеп торучанлык тәрбияләү (толерантность);
- балаларга әхлак тәрбиясе, патриотик тәрбия бирү;
- балалар белән сәламәтләндерү эшләре алып бару, сәламәт яшәү рәвеше тәрбияләү;
- мәктәптә һәр баланың сәләтен ачыклауга юнәлтелгән уңай психологик шартлар булдыру;
- балаларның эшчәнлеген активлаштыру;
- коллективларда тәрбия эшен үстерү;
- гаилә тәрбиясен үстерү.

Мәктәптә педагогларның тәрбия эше 3 очракны күздә тота: укыту барышында, дәрестән тыш эшчәнлектә, мәктәптән тыш эшчәнлектә.
Дәрестән тыш эшчәнлек ике өлешкә бүленә: сыйныф белән эшчәнлек һәм учреждение күләмендәге эшчәнлек. Балаларның иҗади сәләтләрен үстерүгә зур игътибар бирелә. Учреждение күләмендә даими үткәрелә торган бәйрәмнәр белән бергә төрле темаларга карата кичәләр, рәсем һәм сочинение конкурслары, КВНнар, очрашулар, курчак театрлары, әкиятләрне сәхнәләштерү, викториналар, күңелле стартлар, спорт ярышлары һәм бәйрәмнәре уңышлы үткәрелеп килә.

Тәрбия эшен алып баруда сыйныф сәгатьләре зур роль уйный. Сыйныф сәгатьләре укытучы белән балаларның аралашуында төп чара булып тора. Моннан тыш табигатькә экскурсиягә чыгу, бергәләшеп башкарылган эшләр, учреждение күләмендәге чараларга әзерлек, өмәләр коллективны берләштерүгә уңай йогынты ясый.

Тәрбия эше түбәндәге юнәлешләр буенча алып барыла:

- **Физкультура һәм сәламәт яшәү юнәлеше. Сәламәтлекне саклау, иминлекне саклау.**

- иртәнге зарядка;
- дәресләрдә физкультминуткалар;
- сәламәтлек почмаклары;
- балаларның һәм укучыларның грippка каршы иммун системасын ныгыту;
- сәламәтлек көннәре, саф һавада сәламәтлек көннәре;
- күңелле стартлар;
- юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнү максатыннан викториналар, ярышлар;

- чаңгы ярышлары;
- сәламәтлекне саклау һәм начар гадәтләрдән саклану максатыннан сыйныф сәгатьләре, әңгәмәләр;
- Ватанны саклаучылар көненә багышланган конференция;
- язгы су басулар вакытында профилактик чаралар;
- юл йөрү куркынычсызлыгы һәм янгын куркынычсызлыгы буенча, гадәттән тыш хәлләр буенча инструктажлар үткәрү;
- җәйге чорда иминлекне саклау;
- төрле чараларга карата рәсем конкурслары.

- **Патриотик тәрбия.**

Патриотик тәрбия бирү – әйдәп баручы юнәлеш булып кала. Аның максаты булып, гражданлык позициясен формалаштыру, Туган илебез, туган телебез, халкыбызның гореф-гадәтләре белән горурлану хисе, Өлкән буынга, Бөек Ватан сугышы ветераннарына хөрмәт тәрбияләү тора.

- Өлкәннәр көне – олыларга карата мәхәббәт һәм хөрмәт хисе тәрбияләү;
- Укытучылар һәм Тәрбиячеләр көне;
- Аналар көне – әниләргә хөрмәт хисе тәрбияләү;
- балаларның иҗади сәләтен үстерү максатыннан Яңа ел бәйрәме;
- Әлифба бәйрәме;
- Ватанны саклаучылар көне;
- Туган тел көне;
- Халыкара хатын-кызлар көне – әхлак тәрбиясе;
- Нәүрүз бәйрәме – халкыбызның милли традицияләре һәм гореф-гадәтләренә мәхәббәт тәрбияләү;
- Тукай көннәре атналыгы – әдәбият белән кызыксыну тәрбияләү;
- батырлык дәресләре;
- сугыш һәм тыл ветераннарын искә алу;
- Бөек Ватан сугышына багышланган рәсем күргәзмәләре;
- Җиңү көне уңаеннан тантаналы митингта катнашу;
- башлангыч сыйныфлар һәм балалар бакчасы белән саубуллашу бәйрәме;
- Балалар сабан туе – балаларның иҗади сәләтен үстерү максатыннан үткәрелә.

- **Экологик тәрбия һәм хезмәт тәрбиясе**. Туган як табигатен өйрәнү һәм саклау, балаларга хезмәт тәрбиясе бирү максатыннан.

- әйләнә – тирәне саклау буенча чаралар үткәрү;
- “Агач утырт” акциясендә катнашу;

- бүлмә гөлләрен тәрбияләү;
- Экология атналыгы – табигатькә мәхәббәт һәм сакчыл караш тәрбияләү;
- учреждение тирәсендә чәчәкләр утырту, аларны тәрбияләү;
- учреждение тирәсен чистартуда катнашу;
- кошларга җимлекләр, сыерчык оялары ясау;
- Бөтендөнья кошлар көнен билгеләп үтү;
- табигать почмакларын яңарту.

- **Хокук бозуларны булдырмау өстендә эш.**

- Кече яшьтәге балаларның хокукларын яклау инспекторлары белән очрашу;
- Юл йөрү кагыйдәләрен саклау буенча әңгәмәләр үткәрү;
- Үз-үзеңне тоу әдәбе турында профилактик әңгәмәләр үткәрү;
- Кече яшьтәге балалар арасында тәртип бозуларны булдырмау максатыннан эти-әниләргә консультацияләр уздыру;
- куркынычсызлык кагыйдәләре буенча инструктажлар үткәрү.

## БАЛАЛАРНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕГЕ ТОРЫШЫ, ТУКЛАНУНЫ ОЕШТЫРУ, СӘЛАМӘТЛЕКЛӘРЕН САКЛАУ ҺӘМ НЫГЫТУ

Балаларга уңай шартлар тудыру өчен без: дәресләр челтәрен СаНПиН таләпләренә туры китереп төзибез, дәресләрдә физкультминуткалар, күзләр өчен күнегүләр үткәрелә, балалар рәтләр буенча утыртылган, Мәктәпкәчә яшьтәге һәм укучы балалар өчен чыгарылган җиһазлар нормативы саклана.

Бездә балалар һәм хезмәткәрләрнең имгәнү очраклары теркәлмәгән.

Балалар бакчасында балаларны сәламәтлеген саклау һәм ныгыту өчен чыныктыру процессына зур игътибар бирелә:

-иртәнге гимнастика;
-витаминлы туклану оештыру;
-үлән чәйләре эчү;
-тамак чайкату;
-сулыш гимнастикасы;
-сәламәтлек сукмагыннан йөрү;
-җәй көне яланаяк йөрү;
-нокталы массаж;
-һава, кояш ванналары;
-физкультура шөгыльләре;
- саф һавада хәрәкәтле уеннар;
- вакцинация (эти-әниләр ризалыгы белән);
- кварцлау (һәркөнне)

Болар барысы да баланың физик үсешенә уңай йогынты ясап: хәрәкәт активлыгын үстерергә ярдәм итә.

- Посещаемость за 2016 год – 80%;
- Индекс здоровья – 92%;
- Посещаемость дней одним ребенком – 253 дней;
- Пропущенных дней одним ребенком- 49 дней;
- Пропущенных одним ребенком по болезни – 3 дня;

**Укучыларның һәм балаларның сәламәтлек төркемнәре буенча бүленеше (2017-2018 уку елы)**

| Балалар | Саны | Сәламәтлек төркемнәре | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | I | II | III | IV |
| Укучылар | 11 | 3 | 8 | - | - |
| Мәктәпкәчә балалар | 12 | 4 | 8 | - | - |

**Укучыларның физкультура төркемнәре буенча бүленеше**

| Балалар | Саны | Физкультура төркемнәре | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | төп | әзерлек | махсус | азат ителүчеләр |
| Укучылар | 11 | 11 | - | - | - |

Балаларның сәламәтлеген дөрес туклануданн башка күз алдына да китереп булмый. Дөрес туклану баланың үсүенә, физик, психик үсешенә, әйләнә-тирәнең тискәре тәэсиреннән саклануга ярдәм итә. Шулай ук дөрес туклану балаларда туклану культурасы тәрбияләргә ярдәм итә. Көндәлек дежурлар билгеләнә, алар ризык таратырга булышалар.

Туклануны оештыру буенча җаваплылык тулысынча директорга йөкләнә, шулай ук завхоз һәм бракераж комиссиясе дә җаваплы. Балалар бакчасында туклануны оештыру өчен МУП “Туклану департаменты” белән килешү төзелә. Ул безгә СанПин 2.4.1. 3049-13 таләпләренә туры килә торган 10 көнлек меню тәкъдим итә. Атнага 3 мәртәбә азык –төлек китерелә. Ипи, сөт – үзебезнең районныкы булса, башка азык-төлекне департамент үзе китерә. Ай саен департамент хезмәткәрләре килеп азык-төлекне саклау, куллануны тикшерәләр, пробалар алалар. Туклану режимы саклана: иртәнге аш, икенче иртәнге аш, төшке әбәт, полдник. Хөрмәтле әти-әниләр, баланың көндәлек туклану рационы белән танышу сезгә гаиләдә кичке ашларны төрләндерергә ярдәм итә дип уйлыйм. Шул максаттан без сезне көндәлек меню белән таныштырып барабыз.

Мәктәптә дә балалар кайнар аш белән тәэмин ителгән, тукланучы балалар саны – 100%. Ашау 12.40 сум, мәктәп бакчасында җитештерелгән

яшелчәләрне куллану – 5.30 сум, компенсация – 7.10 сум. Мәктәптә туклану 12 көнлек меню белән башкарыла. Ата- аналар туклану белән кәнагәть. Ата-аналар түләве оештырылмаган.

Учреждениедә азык-төлекне саклау һәм ашарга әзерләү бүлеге бар, 1- 4 сыйныф балаларын ашату бүлмәсе оештырылган, балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр үз бүлмәләрендә тукланалар.

Әзерләнгән азыкның куллану вакыты, сыйфаты көндәлек тикшерелеп барыла һәм махсус журналда теркәлә.

Ел саен Учредитель тарафыннан төзелгән комиссия туклануны тикшерә. Аның составына Яшел Үзән ветераннар Советы әгъзалары да керә. Алар бөтен яктан да тикшерәләр: азык-төлек документларын, азык-төлекнең саклану срокларын, шартларын, кухны җиһазларын, пищеблокның санитар халәтен, әзер ризыкны һ.б. Тикшерүчеләр тарафыннан ашханә эшчәнлегенә кагылышлы кисәтүләр ясалмады.

Балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту максатыннан медицина тикшерүләре, диспансеризация һәм сәламәтлек дәрәҗәсен билгеләү диагностикалары үткәрелә. Уку елы барышында Сәламәтлек көннәре уздырыла.

Учреждениедә санитар-гигиена таләпләре үтәлә. ФАП фельдшеры белән тыгыз элемтә саклана. Фельдшер профилактик темаларга әңгәмәләр үткәрә, балаларның сәламәтлеген күзәтә һәм медицина ярдәмен күрсәтә. Соңгы өч уку елында балалар арасында имгәнү очраклары теркәлмәгән.

Педагогик коллектив сәламәт шәхес тәрбияләү өстендә эшли. Учреждениедә сәламәтлек һәм иминлекне саклауның төп максаты - балаларда сәламәт яшәешкә омтылыш, сәламәтлекнең иң кирәкле байлык булуына төшендерү.

## АТА-АНАЛАР БЕЛӘН ЭШ

Учреждение хезмәткәрләре ата-аналар белән һәрвакыт элемтәдә тора. Ел дәвамында 4 гомуми, шулай ук төркем һәм сыйныфларда җыелышлар уздырылды.

Ата-аналар һәрдаим бәйрәмнәргә чакырыла, бергәләп бәйрәмнәр, ачык ишекләр көннәре уздырыла, балаларның һәм эти-әниләрнең иҗади эшләре күргәзмәсе оештырыла.

Ата-аналар өчен «Гаилә һәм балалар бакчасы хезмәттәшлегендә актуаль проблемалар», «Баланың үз-үзенә йомылуы", «Балалар сәламәт булсыннар!» темаларына күчмә папкалар; "Эш яратып үссеннәр", "Балалар бакчасында әкият терапия һәм бармак уеннары", "Өйдә балалар белән ничек шөгыльләнергә", "Балаларага фольклор ярдәмендә әхлак тәрбиясе бирү", "Һәр сабыйның күңеленә ачкыч табыйк", «Балаң мәктәпкә әзерме?» темаларына әңгәмә, консультацияләр үткәрелде. «Мәктәп тормышы», "Балалар бакчасында уку-укыту һәм тәрбия", "Әти, әни – син нинди"

темаларына ата-аналар белән  анкеталар, тестлар үткәрелде. Ата-аналар тарафыннан бакча эшчәнлеге уңай бәяләнде. Май аенда ата-аналары белән сыйныфларда һәм төркемдә йомгаклау җыелышлары үткәрелде,  балаларның диагностика нәтиҗәләре, мәктәпкә керүче баланың мониторинг нәтиҗәләре белән таныштырдык, җәйге чорга инструктаж үткәрдек, киңәшләр бирдек.

## ИМИНЛЕКНЕ ТӘЭМИН ИТҮ

Балаларның һәм хезмәткәрләрнең иминлеген тәэмин итү максатыннан учреждениедә янгынны хәбәр итү чаралары каралган: сигнализация һәм янгын сүндерү җайланмалары, видеокүзәтү камералары, ут сүнгән очракта өстәмә яктырту,  үзәк янгын бүлегенә хәбәр итүче төймә (Стрелец-мониторинг) һәм полиция бүлегенә хәбәр итүче төймә (кнопка тревожной сигнализации)урнаштырылган.

Янгын чыгу очрагына каралган эвакуация планы  ГОСТ Р.2.12.143-2002 ППБ 01-03.п3 (стандартларга) туры килә. Эвакуация юлларын аңлатучы инструкция белән учреждениенең барлык балалары һәм  хезмәткәрләре таныштырылган.

Учреждение зданиесендә 3 эвакуация юлы каралган. Мәктәптә тәүлек буе сак оештырылган: көндез-дежур торучы кизү, төнлә-каравылчылар. Учреждение тирәсендә өстәмә яктырту лампасы бар. Шулай ук учреждение тирәсе койма белән әйләндереп алынган, керү капкалары һәрвакыт ябык.

Хезмәт саклау буенча тиешле документлар, куркынычсызлык паспорты эшләнгән. Учреждение администрациясе тарафыннан балаларның иминлеген саклауга өстенлек бирелә.

Иминлеккә өйрәтү йөзеннән түбәндәге комплексллы чаралар үткәрелә:

1. «Тревога» сигналы буенча эвакуациягә өйрәнүләр.
2. Тормыш иминлеге нигезләре буенча сыйныф сәгатьләре.
3. Куркынычсызлык кагыйдәләрен аңлату буенча инструктажлар.
4. Юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнү һәм ныгыту максатыннан уку елы дәвамында төрле тәрбия чаралары үткәрелә.

Хөрмәтле әти-әниләр сезгә дә мөрәҗәгать итәм: куркынычсызлыкны тәэмин итүдә сез дә катнашыгыз – капкаларны артыгыздан ябып йөрегез, сезнең белән мәктәп-бакча бинасы тирәсенә килүче чит кешеләргә игътибар итегез, территорияне чүпләмәгез. Болар да безнең иминлеккә карый.

| Эш юнәлешләре<br><br>Үткәрелгән чаралар | Хезмәтне саклау | Янгын куркынычсызлыгы | Терроризм куркынычсызлыгы | ТИН (укучылар, балалар) |
|---|---|---|---|---|
| Квалификация күтәрү | План нигезендә 1 кеше | План нигезендә 1 кеше | - | 100% |
| Инструктажлар үткәрү | 100% | 100% | 100% | 100% |
| Контроль-идарә чаралары | по плану учреждения в полном объеме | | | |
| Профилактик чаралар | информацион стендлар, видеоматериаллар, конкурсларда катнашу, 1 педагогик утырыш, ай саен производство утырышлары | | | |
| Эш урынын аттестацияләү | 100% | Акт | Акт | |
| Тренировкалар | По плану учреждения и округа | | | |
| | Елга 1 мәртәбә | 4 тапкыр (справка, акт, журнал) | 4 тапкыр (справка, акт, журнал) | 4 тапкыр (журнал) |
| Объектларга техник күзәтү | көндәлек | | | |

## ҖӘМӘГАТЬЧЕЛЕК БЕЛӘН ЭШ

Ел дәвамында балалар белән авыл мәдәният йортында “Өлкәннәр көне”, “Яңа ел”, “8 март”  9 май һ. б. бәйрәмнәр үткәрелде. Спорт клубына йөрүче балалар  физик яктан да, рухи яктан да чыныгу алалар, шулай ук алар ел дәвамында ярышларда катнашып, җиңүләр яуладылар. Җиңү көненә багышланган митингта катнаштык. Авыл китапханәсе белән берлектә район күләмендә үткәрелгән чараларда катнашып балалар диплом, грамоталар, истәлекле бүләкләр белән бүләкләнде. Кибет, пункт, урманнарга экскурсияләр оештырылды, Күмәк хуҗалык эшчәнлеге белән якыннан таныштылар. Мондый чараларда балалар бик теләп катнаша. Күмәк хуҗалык җитәкчесе Ирек Галимович  хуҗалык эшләрендә ярдәм итә. Җирле үзидарә җитәкчесе Фәния Хәбибулловна белән һәрдаим киңәшләшеп эшлибез. Быел ул безгә Янгын надзоры тарафыннан бирелгән предписаниедә күрсәтелгән пунктларга сметаларга ясарга ярдәм итте.Безнең учреждениегә янгын сүндерү гидранты кирәк, аны урнаштыру 60000 тирәсе тора. Шулай ук икенче пункт - мәктәпкә зур капкадан керә торган юл федераль трасса саналган юлга кадәр таш белән түшәлергә тиеш. Аңа 250000 тирәсе акча кирәк. Былтыр да бу ике пункт үтәлмәде, Мировой судья безне 90 000 штрафка тартты. Вакытында түләмәсәк бу сумма икеләтә өстәлеп безнең өскә эленәчәк иде. Хәзерге вакытта сметалар казначейтвога тапшырылды.




## ЭКОНОМИК ЭШЧӘНЛЕК

Учреждениене финанс яктан тәэмин итү түбәндәге юллар белән башкарыла:
- Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы бюджеты;
- Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы кануннары карары нигезендә билгеләнгән күләмдә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы бюджеты хисабына;
- эшмәкәрләр һәм башка табыш китерүчеләр хисабына.

2017 елда һәр бала өчен бүлеп бирелгән бюджет акчалары балалар бакчасы һәм мәктәптә алып барыла торган уку-укыту программаларын тормышка ашыру, педагогларның хезмәт хакын түләү, коммуналь уңайлыкларны түләүгә, килешүләр төзүгә тотылды.

ПФХД үтәлеше отчеты, 2017 ел

| **Наименование показателя** | **Сумма, в руб.** |
|---|---|
| Расходы на выплату заработной платы персоналу с начислениями | 3 281 848,82 |
| Уплата налогов | 23 945,87 |
| Услуги по содержанию имущества Закупка товаров, работ, услуг | 1 253 384,05 |

| | |
|---|---|
| Организация питания | 346 950,40 |
| ИТОГО | 4 906 129,14 |

ПФХД планы, 2018 ел

| Наименование показателя | Сумма, в руб. |
|---|---|
| Расходы на выплату заработной платы персоналу с начислениями | 3 210 253,00 |
| Уплата налогов | 25 296,66 |
| Услуги по содержанию имущества Закупка товаров, работ, услуг | 1 221 977,23 |
| Организация питания | 311 203.32 |
| ИТОГО | 4 768 730,21 |

**2018-2019 уку елына бурычлар**

1. ФЗ “Об образовании в Российской Федерации”, ТР Мәгариф турындагы, ТР халыклары телләре турындагы законнарны тормышка ашыру.
2. Башлангыч мәктәп һәм балалар бакчасында укыту-тәрбия эшен федераль дәүләт стандартларына туры китереп алып бару.
3. Уку-укыту процыссында катнашучыларның куркынычсызлыгын тәэмин итү.
4. Балалар коллективы белән эшләү алымнарын камилләштерү.
5. Сәләтле балалар белән эшләүнең яңа алымнарын куллану.
6. Балаларның сәламәтлеген ныгыту өстендә эшләү.
7. Балалар бакчасы, мәктәп, гаилә арасындагы элемтәне ныгыту, гаилә белән эшләү юлларын төрләндерү, гаилә-педагог-бала үсеше өчен эшчәнлекнең яңа алымнарын кулланырга
8. Благоустройство буенча проблемаларны хәл итү юлларын эзләү. Ә алар бүгенге көнгә: мәктәп - бакча бинасының түбәсен алыштыру, тәрәзәләрне алыштыру, тышкы ишекләрне алыштыру. Предписание буенча янгын куркынычсызлыгы өчен гидрант урнаштыру, алдан аталган юлга таш җәйдерү, территория периметры буенча 1 якка тимер сеткадан койма тоту, балалар уен мәйданчыгын җиһазлар белән тәэмин итү.